**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елда Актаныш муниципаль районында Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елын әзерләү һәм үткәрү турында

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның «Татарстан Республикасында 2023 елны Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы дип игълан итү турында» 2022 елның 20 октябрендәге ПУ-750 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр һәм Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елын уздыру буенча оештыру комитетының уртак утырышы беркетмәсенең 11 пунктын үтәү йөзеннән,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Актаныш муниципаль районында Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты составын расларга (1нче кушымта).
2. Актаныш муниципаль районында Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы чаралары планын расларга (2 нче кушымта).
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.М.Әнвәровага йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Ильясов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкче
карарына __________ 2023 ел, №-__
1 нче кушымта

Актаныш муниципаль районында Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты составы

Ильясов Р.А.- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе;
Әнвәрова Д.М.- Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары.

Комиссия әгъзалары:

Вахитов И.И. Муниципаль район Башлыгы Аппараты җитәкчесе;

Сираева Л.Р.- Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары;
Гилаева М.З. - Муниципаль район Советының оештыру эшләре бүлеге башлыгы;

Шакирова Р.М. - Актаныш муниципаль районының «Мәгариф идарәсе» башлыгы;
Латипов Н.Н. - Социаль һәм агарту эшләре бүлеге башлыгы;

Вәлиев Л.Ә. - Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы;

Мөхәмәдиева Г.Б.- Башкарма комитетның ЗАГС бүлеге җитәкчесе;

Галимҗанова А.Р.- Башкарма комитетның архив бүлеге башлыгы;

Хуҗахметова Г.Ф. - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Актаныш муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча);

Гыймадиев А.Р.- «Актаныш МРҮ» ААҖ «Татмедиа» филиалы директоры (килешү буенча).

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкче карарына
__________ 2023 ел, №-__
2 нче кушымта

**Актаныш муниципаль районының 2023 елга милли мәдәниятләр һәм традицияләр елын әзерләү һәм үткәрү буенча чаралар планы**

| № | Чараның атамасы | Үткәрү вакыты | Уздыру урыны | Башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елын, Россия Федерациясендә педагог һәм остаз елын ачу | гыйнвар | Актаныш РДК | РДК, ДШИ, Башкарма комитет, ГАУК РТ «Агыйдел» , Авыл хуҗалыгы идарәсе. |
| 2 | Район алдынгылары слеты | гыйнвар | Актаныш РДК | РДК, ДШИ, Башкарма комитет, ГАУК РТ «Агыйдел» |
| 3. | «Методик тупланма» (балалар, педагоглар, ата-аналар өчен методик эшләнмәләр, тематик әдәбият сайлау. | гыйнвар | Мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләре | «Мәгариф идарәсе» МКУ, мәктәпкәчә балалар учреждениесе мөдирләре һәм гомуми белем бирү учреждениеләре директорлары |
| 4 | Татарстан Республикасында милли мәдәниятләр һәм традицияләр елына багышланган сәнгать һәм методик әдәбият күргәзмәсен оештыру. | февраль | Актаныш | «АМЦБ» МБУ «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 5. | «Балаларны татар халык мәдәнияте чыганакларына җәлеп итү» (педагоглар өчен консультация) | февраль | Мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләре | «Мәгариф идарәсе» МКУ |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 6. | «Тел-халыкның тере хәтере, аның җаны, аның байлыгы» туган телләр көненә багышланган чаралар. Үткәрү формалары: викториналар, уеннар, иҗади биремнәр үтәү | 21 февраль | Мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләре | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 7. | «Татарстанның халык кәсепләре» | март | Мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләре | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 8. | «Нәүрүз» бәйрәме | март | Актаныш «Бүләк» урман массивы | Балалар иҗат үзәге «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 9. | Халыкара хатын-кызлар көненә багышланган тематик бәйрәм. Район милли культураларының район күргәзмәсе | март | Район мәдәният йорты | МБУ «АМЦБ», АДШИ, РДК, ГАУК РТ «Агыйдель» |
| 10. | «Тукай безнең күңелләрдә» Бөек шагыйрь Габдулла Тукайның тууына 137 ел тулуга багышланган тантаналы чаралар. | апрель | Район мәдәният йорты | «Мәгариф идарәсе» МКУ, социаль һәм агарту эшләре бүлеге |
| 11. | «Көнчыгыш Кама аръягы татар авыллары» китабын район тәкъдир итүе (махсус программа) | 1 кв. | Актаныш, РДК | МБУ «АМЦБ», РДК, Башкарма комитет |
| 12 | ТР Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елына багышланган иҗат коллективларының район смотры. | ел дәвамында, 2-3 кв. | Актаныш районы, ТР, төбәкләр. | Башкарма комитет, ОСПР, РДК, СДК, метод. каб. СП. |
| 13. | Театр коллективларының район смотры | 2,3 кв. | районның авыл җирлекләре, РДК | Башкарма комитет, ОСПР, РДК, СДК, метод. каб. СП. |
| 14. | Халык шагыйренең 101 еллыгына - Гамил Афзал исемендәге республика әдәби фестиваль-конкурсы | 1-2 кв. | Актаныш РДК | МБУ «АМЦБ», РДК, Башкарма комитет |
| 15. | «Сезнең гаиләдә халык традицияләре» онлайн-квизы | 1-2 кв. | «Яшьлек» яшьләр үзәге МБУ | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| 16. | «Мин татарча сөйләшәм» халыкара акциясе хөрмәтенә «Ә син беләсенме?» викторина шоу-тамашасы | 1-2 кв. | «Яшьлек» яшьләр үзәге МБУ | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| 17. | Милләтләр һәм традицияләр елына багышланган республика, төбәкара конкурсларда («Ел хатын-кызы», «Минем шәҗәрә», «Уйна гармун», «Йолдызлык», «Сандугач сайрар ил» һ.б.) иҗат коллективларының катнашуы | ел дәвамында | | Башкарма комитет, РДК, авыл мәдәният йорты, метод.каб СП. |
| 18. | Юбилей иҗат чаралары ( М.Мирзаның , А.Тимершәехның 70 еллыгы һ.б. | 1-3 кв. | Актаныш РДК Сабантуй мәйданы | МБУ «АМЦБ», РДК, АМЦБ |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 19. | Гомуми белем бирү оешмалары арасында КВН район лигасы | 1-2 кв. | «Яшьлек» яшьләр үзәге МБУ | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| 20. | «Авыл vibe» проекты (кичке авыл ялы) | 1-2 кв. | | «Яшьлек» яшьләр үзәге МБУ, авыл җирлекләре |
| 21. | «Һәр йортта - үз уенчыклары» ( уенчыкларның төрле төрләре турында күргәзмә). | апрель | Балалар иҗат үзәге | Балалар иҗат үзәге «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 22. | «ТР Актаныш сәнгать мәктәбе»нең хисап-иҗади концерты | май, гыйнвар | | «ТР АДШИ» МБУ |
| 23. | «Татар йорты» (музейларны, мини-музейларны, почмакларны яңа экспонатлар белән тулыландыру) | май | гомуми белем бирү учреждениеләре | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 24. | «Карга боткасы» бәйрәме | 1 нче май | Актаныш «Бүләк» урман массивы | Балалар иҗат үзәге «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 25. | Актаныш муниципаль театрының РСФСРның халык артисты Әлфия Авзалованың 90 еллыгына багышланган «Әлфия» спектакленең премьерасы. Театр гастрольләре | ел дәвамында | Актаныш РДК, районның театр мәйданчыклары, Татарстан һәм Башкортстан Республикасы | «АРДК» МБУ, муниципаль театр |
| 26. | Район авыл җирлекләренең иҗади җәйге фестивале (аерым программа, театр коллективлары смотры, район үзәгендә авыл көннәре) Актаныш, КВН конкурсы, фольклор бәйрәмнәре («Капка төбе», «Печән өсте», «Боз китү», һәм башкалар), яңа ел ярминкәләре, «Ярминкә-базар», фольклор фестивале һ.б.). | 2-3 кв. | Парклар, скверлар АҖ, УК, сабан туе мәйданчыклары һ.б. | РДК, метод. үзәк, авыл мәдәният йорты, СК, китапханәләр |
| 27. | «Актаныш районы проектлары картасы» районның иҗади проектларын оештыру:<br>«Байсар базары»<br>«Риза Ишморат фестивале»<br>«Елга бәйрәме»<br>«Пристань көне»<br>«Шырлык чаналары»<br>«Михайловка көне» | 2-3 кв. | Байсар, Кәзкәй, Уразай, Тат.Ямалы, Әҗәкүл, Михайловка | РДК, метод. үзәк, авыл мәдәният йорты, СК, китапханәләр |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 28 | Районның милли мәдәният бәйрәмнәрен («Семык», «Нәүрүз», «Сабантуй», «Ураза бәйрәме», «Корбан бәйрәме» һ.б.) үткәрү. | ел дәвамында | | РДК, метод. үзәк, авыл мәдәният йорты, СК, китапханәләр |
| 29 | «Актаныш гармуннары» ачык гармунчылар фестивале, район гармунчылар десанты | 2-3 кв. | | «Иске Сәфәр мәдәният йорты» МБУ, район мәдәният йорты, метод. үзәк, авыл мәдәният йорты, СК, китапханәләр |
| 30 | Әдәби Сабантуй | 2-3 кв. | Сабантуй территориясе | МБУ «АМЦБ», китапханәләр |
| 31 | «Татар балалар фольклоры дөньясы» иртәләре | июнь | Мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләре | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 32 | «Сабантуй» милли бәйрәмен үткәрү | июнь | | Актаныш районы Советы, авыл җирлекләре |
| 33 | «Бердәмлектә - ил көче» (асфальтта рәсемнәр конкурсы) | июнь | Мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләре | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 34 | «Ромашкалар - мәхәббәт чәчәкләре» гаилә акциясе | июль | «Яшьлек» яшьләр үзәге МБУ | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| 35. | «Безнең әби-бабайлар уеннары» (милли мәдәниятне өйрәнү һәм пропагандалау) | июль | «Бүләк» белем бирү-сәламәтләндерү үзәге | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 36. | «Татар милли бизәкләре» | июль | «Бүләк» белем бирү-сәламәтләндерү үзәге | «Мәгариф идарәсе» МКУ, МБОУ «Бүләк» белем бирү-сәламәтләндерү үзәге директоры |
| 37. | «Минем Татарстан чәчәк атсын!» тантаналы чаралар, бәйрәм концертлары, әдәби-музыкаль кичәләр, күңел ачу программалары, авылдашларның Татарстан Республикасы көненә багышланган очрашулары | август | | Актаныш районы Советы, авыл җирлекләре |
| 38. | «Фолк-дәрес» (мәктәп укучылары белән гореф-гадәтләрне өйрәнү дәресе) | сентябрь | Мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләре | «Мәгариф идарәсе» МКУ |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 39. | «Синең йортыңа тынычлык » (Татар милли ашларын әзерләү бәйгесе.) | сентябрь | Мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләре | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 40. | ТР ГАУК «Агыйдел» һәм Актаныш коллективларының Казан шәһәрендәге иҗат концерты | Август-сентябрь | ТР ДАУК «Агыйдел», Казан шәһәре | ТР ГАУК «Агыйдел» |
| 41. | Казахстанның Алма-Ата шәһәрендә төбәкара федераль милли Сабантуй бәйрәмен оештыруда һәм үткәрүдә катнашу | 3 кв. | Казахстан Республикасы Алма-Ата шәһәре | РДК, ДШИ, Башкарма комитет, РТ ГАУК «Агыйдел», Авыл хуҗалыгы идарәсе, яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| 42. | «Милли кәсепләр» (Көзге ярминкәдә катнашу) | октябрь | | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 43. | «Сөмбелә» бәйрәме (Уңыш бәйрәме - Сөмбелә) | октябрь | Мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләре | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 44. | К.К.Әдгамов исемендәге район үзәге авылларын, предприятиеләрен, оешмаларын төзекләндерүгә район конкурсы | ел дәвамында | район буенча | РДК, метод. үзәк, авыл мәдәният йорты, СК, китапханәләр |
| 45. | Актаныш муниципаль районы мәдәният хезмәткәрләре Сабантуе | 3 кв. | Киров авыл мәдәният йорты территориясе | РДК, метод. үзәк, авыл мәдәният йорты, СК, китапханәләр |
| 46. | «Минем бөек Россия...» (Халыклар бердәмлеге көненә багышланган чаралар) | ноябрь | | |
| 47. | «Татар егете. Татар кызы - 2023» | ноябрь | | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 48. | « Оста куллар күңелсезлекне белми » күргәзмәсе (ТР милли мәдәният һәм традицияләр елына багышланган эшләр күргәзмәсе).) | ноябрь | Балалар иҗат үзәге | «Мәгариф идарәсе» МКУ, «Балалар иҗат үзәге» МБМУ |
| 49. | «Туган илем - Татарстан!» интеллектуаль квиз-уены | ноябрь | «Яшьлек» яшьләр үзәге МБУ | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| 50. | «Минем күпмилләтле илем» квест-уены (Максаты: Россиянең төрле халыклары, милләтләре турында белем бирү, балаларны «милләт», «мәдәният» төшенчәләре белән | декабрь | гомуми белем бирү учреждениеләре | «Мәгариф идарәсе» МКУ |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | таныштыру, музыка, төрле халыклар биюләре турында белемнәр формалаштыру, төрле милләтләргә толерант мөнәсәбәт тәрбияләү) | | | |
| 51. | «Минем туган поселогым» (Проект-тикшеренү эше.<br>Милли мәдәниятләргә һәм традицияләргә багышланган иҗади, фәнни-тикшеренү, мәгариф, мәгълүмат һәм нәшрият проектларын гамәлгә ашыру һәм яклау) | декабрь | гомуми белем бирү учреждениеләре | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 52. | СВО га багышланган район чаралары | ел дәвамында | Район буенча | РДК, метод. үзәк, авыл мәдәният йорты, СК, китапханәләр,ДШИ |
| 53. | Актаныш районыннан чыккан  мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренең, торак пунктларның, предприятиеләрнең, оешмаларның, юбилей даталары белән бәйле тантаналы бәйрәм чаралары | ел дәвамында | Район учреждениеләре, оешмалары, предприятиеләре | РДК, ДШИ, Башкарма комитет, ГАУК РТ «Агыйдел» |